# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Шумково авыл җирлегенең Шумково торак пунктында**
**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**

**2024 елның 20 ноябере** **№ 23**

«Россия Федерациясендә җирле үз идарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үз идарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белеем алучы студентлардан һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 төркем инвалидлардантыш, 500 (биш йөз) сумм күләмендә үз ара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- халык өчен масса күләм ял итү урыннарын (парклар, мәйданнар, ярлар, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итү урыннары) урнаштыру һәм ремонтлау һәм күрше территорияне яхшырту;
- су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлауга, аны чистартуга, транспортлауга һәм халыкка су бирүгә (җибәрүгә);
- урам яктырту җайланмасы;
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларыт өзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерүгә;
- кышкы юлны тоту;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдалануда гыҗирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково торак пунктының түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында:Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урам, 4 нче йорт, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А. Р. Гилазиева.

Шумково авыл җирлеге башлыгы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Татарстан Республикасы А. Р. Гилазиева.